СООВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 4-05-21; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamaduYsh.tatarstan.ru

Решение | Карар
№2-22 | 20 февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш күл авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 июнендәге 1-33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендәҗирлеүзидарәнеоештыруныңгомумипринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Катмыш авылҗирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 июнендәге 1-33 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Җәмәгать тыңлауларын (җәмәгатьчелекфикеральшуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»1-33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кушымтаның 12 статьясындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, шәһәр округларының генераль планнары (алга таба әлеге статьяда – иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар) буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы И.Г.Габидуллинга йөкләргә.

Катмыш
авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы И.Г.Габидуллин